СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Габделхая Каримова, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**22 март 2024 ел** **№7**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча 2024 елның 7 нче апреленә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.
2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча 2024 елның 7 нче апреленә 12 сәгать 00 минутта билгеләргә.
3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча 2024 елның 7 нче апреленә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.
4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча

халык җыенының дүртенче этабын Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1в йорт адресы буенча 2024 елның 7 нче апреленә 16 сәгать 00 минутта билгеләргә.

5. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Тукай урамында яшәүчеләр.

2нче этап: Такташ, Урак һәм Чүкеч, Тынычлык урамында яшәүчеләр.

3нче этап: Габделхэй Кэримов, Яшьләр, Төньяк, Яр буе урамында яшәүчеләр.

4нче этап: Сәгъдуллин, Җиңү, Бакча урамында яшәүчеләр.

6. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар жыены нәтижәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарында гражданнар жыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

"Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 325 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 650 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Шушмабаш авылы Яшьләр урамында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Шушмабаш авылында Габделхэй Кәримов урамына балалар мәйданчыгы сатып алу);
- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Шушмабаш авылында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 20 данә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Шушмабаш авылы Төньяк урамында суүткәргеч челтәрен алыштыру);
- гадәти күмү урыннарын коймалап алу, ремонтлау, төзекләндерү (Шушмабаш авылындагы зират территориясеннән агачларны санитар кисү һәм чыгару)
- һәйкәлләр кую, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (Шушмабаш авылы зиратына 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга мемориаль такта ясау һәм урнаштыру)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ""

7. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлегенең Шушмабаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча

халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Габделхәй Кәримов урамы, 1б йорт, Габделхәй Кәримов урамы, 5 йорт, Габделхәй Кәримов урамы 8 йорт адреслары буенча, Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690000210 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1609012678